| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2023 ел №68

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Менделеевск шәһәр Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2.5 пунктын «Махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә идарәче компанияләр тарафыннан танылa торган оешмаларныкы булган җир кишәрлекләренә карата 2028 елга кадәр «0,1% дип үзгәртергә һәм бәян итәргә;».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Мееделеевск шәһәр Советының 2023 елның 30 октябрендәге 60 номерлы "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләре кертү хакында" карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми порталына урнаштырырга Www.mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Шәһәр Советы рәисе Р.И. Беляев

376807 860307

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА МЕНДЕЛЕЕВСКОГО РАЙОНА**
Фомина ул., 11, Менделеевск, 423650

Председателю финансово-бюджетной палаты Менделеевского муниципального района Республики Татарстан

Григорьеву М.В.

21.12.2023 №02-01-13-2023/1015-23-20920022

На №

**ЗАКЛЮЧЕНИЕ**
о соответствии нормативного правового акта

Прокуратурой Менделеевского района Республики Татарстан изучен проект решения городского Совета Менделеевского муниципального района Республики Татарстан «О внесении изменений в решение Менделеевского городского Совета Менделеевского муниципального района Республики Татарстан от 03.11.2020 № 6 «О земельном налоге».

Данный проект не противоречит действующему законодательству.

Замечаний не имеется.

Прокурор района

старший советник юстиции Р.Н. Шакиров

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат 3E824690D217802B24985F669FA23BEC
Владелец **Шакиров Ришат Наилевич**
Действителен с 02.11.2022 по 26.01.2024

А.В. Закиров, тел. (85549) 2-14-88, 016400007

Прокуратура Менделеевского района Республики Татарстан
№ 02-01-13-2023/1015-23-20920022

ОСОБАЯ
ЭКОНОМИЧЕСКАЯ
ЗОНА
АО «Особая Экономическая Зона
Промышленно-производственного
типа «АЛАБУГА»
423600, Республика Татарстан,
район Елабужский, г. Елабуга, а/я 125
Тел.(85557)5-90-05, факс(85557)5-90-04
www.alabuga.ru
e-mail: post@sezalabuga.ru
ОКПО 95427882, ОГРН 1061674037259
ИНН 1646019914, КПП 164601001

__________________№_______________

На №_________________от____________

Татарстан
Республикасы
Менделеевск
муниципаль районы
башлыгы Р.И. Беляевка

Җир салымы буенча ташлама турында

Хөрмәтле Радмир Илдар улы!

Татарстан Республикасының Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары территориясендә сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона булдыру максатыннан (алга таба - «Алабуга» ППТ зонасы), очрашу беркетмәсе Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов белән «АЕОН» ИК ҖЧҖ директорлар советы рәисе Р.В. Троценко очрашу беркетмәсен үтәү йөзеннән 19.05.2023 елның 19 маеннан башлап авыл җирлекләре чикләрен үзгәртү, җир кишәрлекләрен авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән сәнәгать җирләренә күчерү эшләре алып барыла.

РФ Салым кодексының 394 маддәсенең 1 пунктында салым ставкаларының һәм ташламаларның муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары белән билгеләнүе каралган.

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2019 елның 29 октябрендәге 81 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Җир салымы турында» 2017 елның 03 октябрендәге 48 номерлы карарына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәлде:

2.11«идарәче компанияләр тарафыннан «Махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 5 елга билгеләнгән оешмаларныкы булган җир кишәрлекләренә карата 0.1%ы».

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2017 елның 3 октябрендәге 48 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылды, Карарның 2 пункты белән түбәндәге күләмдә җир салымы ставкасы билгеләнде:

«2.5. Оешмалар идарәче компанияләр тарафыннан 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы «Махсус икътисадый зоналар турында» Федераль закон нигезендә танила торган махсус икътисадый зона территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата 0,1 %
2023 елга кадәр шул көнне кертеп;».

3. Татарстан Республикасының Алабуга һәм Менделеевск муниципаль районнары территориясендә «Алабуга» ППТ МИЗ төзүнең эшкәртелү стадиясендә булуын, ә Менделеевск муниципаль районы территориясендә «Алабуга» ППТ МИЗ чигенә кертелергә тиешле җир кишәрлекләренең сәнәгать җирләренә күчерелүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы «Җир салымы турында» карарының 2.5 пункты тәгъбирен
үзгәртү мөмкинлеген карауны һәм түбәндәге редакциядә бәян итү мөмкинлеген сорыйм:

«2.5. идарәче компанияләр тарафыннан «Махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә танила торган оешмаларга караган җир кишәрлекләренә карата 0,1 %, 2028 елга кадәр шул көнне кертеп;».

Шундый ук тәгъбирне түбәндәгеләргә кертергә:

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының 2020 елның 25 февралендәге 163 номерлы
«Җир салымы турында» карарына;

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2020 елның 24 мартындагы 164 номерлы «Җир салымы турында» карарына;

- Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советының 2020 елның 25 февралендәге 143 номерлы
«Җир салымы турында"  карарына

Хөрмәт белән,
Юридик хезмәт башлыгы А.А. Кадыйров

Тел.: (85557)59006 (доб. 6186)